
## Ял минутларында

Сканвордны чишегез




### Хуш киләсез, кошкайлар!

Яз килә, яз белән бергә туган якларыбызга кошлар кайта. Шулар өчен укучыларыбыз оялар әзерләделәр.






**Газетаны оештыручылар:**

татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Вафина Лилия Нуртдин кызы,**

информатика, математика укытучысы

**Фатыйхова Гөлшат Рафис кызы**

**Индекс-** 422017

**Тираж-** 10 данә



**Телефон:** +7843-665-03-11

**E-Mail**: Sua.Ars@tatar.ru, sch525@mail.ru

**Адрес:** ТР, Арча районы, Мәктәп урамы, 44. Муниципаль гомуми белем бирү учреждениесе «Утар-Аты төп гомуми белем мәктәбе”




# ЧИШМӘ БАШЫ


“ Туган телне сөючеләр”нең матбугат үзәге

март 2025 ел

№ 5


*Бу санда*


- 8 март- Халыкара хатын-кызлар көне котлавы ..........................................1
- Мәктәп сулышы..............................2
- Безнең уңышлар..............................3
- Ял минутларында...........................4
- Хуш киләсез, кошкайлар!........……4





Жылы кояш нурларына төренеп, йөгерек гөрләвекләре белән йөгереп язның беренче ае- март та килеп житте. Барыбызга да билгеле, әлеге айның иң матур, иң олы бәйрәме- 8 Март – Халыкара хатын-кызлар көне.

Хөрмәтле укытучы хатын-кызларыбыз, хезмәткәрләр, укучы кызларыбыз- барчагызны да иң күркәм тантаналарның берсе- Халыкара хатын-кызлар көне белән чын күңелдән тәбрик итәбез!

Язның беренче жылы нуры булып керүче бу бәйрәм сәламәтлек, бәхет һәм бәрәкәт китерсен иде! Сезнең тормышыгыз яхшылык һәм яктылык, мәхәббәт, якыннарыгызның күңел жылысы һәм игътибары белән тулып, йөзләрегез елмаюдан яктырып, нурлар чәчеп торса иде!

Язгы гөрләвекләр сезгә эшегездә, укуыгызда зур уңышлар, күтәренке кәеф, бәхет алып килсен!



И хатын-кыз, и изге зат!
Син – жирнең фәрештәсе!
Сүзләр аздыр, килә сиңа
Хис белән эндәшәсе...

Күзләрең – күл, чәчләрең – төн,
Керфекләрең – ярым ай,
Кыйгач кашың – кош канаты,
Йөзең алсу алмадай!

Син – кояшы, син – чәчкәсе,
Син – бизәге жиремнең!
Син – сагышы, син – балкышы
Һәм – син моңы жырымның!

И хатын-кыз – илаһи зат!
Камил синең бар ягың.
Каршылыклар белән тулы
Зур сере син дөньяның!

И хатын-кыз – алиһә зат!
Килә серең чишәсе.
Кешелеккә жан өрүче
Син – тормышның чишмәсе!

*Наил Касыймов*

# Мәктәп сулышы

## Шахмат- ул уен да, көрәш тә, иҗат та.



Тарихы ерак гасырларга тоташкан шахмат уены бүгенге компьютер, гаджетлар дөньясында да популярлыгын югалтмый. Әлеге уенның иң төп әһәмияте – кешенең интеллектуаль сәләтен үстерергә ярдәм итүдә...Халыкара спорт комитеты 1999 нчы елны гына шахматларны спорт төре итеп таный.

Шахмат - акылны чистарта, фикерләргә өйрәтә торган уен. Шахмат тәрбия чарасы буларак та бик файдалы. Уен фигурасына тотынгансың икән - йөр, кулыңны фигурадан алсаң - йөреш санала. Әлеге кагыйдә эшләр алдыннан яхшылап уйларга, үз адымың өчен җаваплылык тоярга өйрәтә.


Шахматлар төптән уйлап эшләргә, тәртипкә өйрәтә һәм укуда да ярдәм итә. Тормыш гел җиңүдән генә тормый бит. Шахматта да шулай. Җиңелүдән курыкмыйча, көчлерәк уенчылардан өйрәнеп шөгыльләнергә кирәк.

Шахматлар берникадәр элитар уен булу белән бергә, бик демократик уен да. Шахмат уйнау өчен стадионнар салу да, кыйммәтле җиһазлар да кирәк түгел. Аны һәрвакыт, һәр җирдә уйнарга мөмкин. Шахмат уены - тормышның үзе шикелле. Фигураларны сакларга, якларга кирәк. Үсәргә, алга барырга кирәк.

Шахмат уены балаларга күп шатлык, рәхәтлек китерүче уен гына түгел, ә аларның акыл үсешен үстерүнең нәтиҗәле чарасы да. Шахмат уенының роле баланың эчке дөньясын формалаштыруда бәяләп бетергесез. Шахмат уйнау хәтерне үстерә, логик фикерләүне үстерүгә ярдәм итә, тырышлык, игътибарлылык, уйланучанлык, максатчанлык тәрбияли. Бу уенны өйрәнүче бала җыйнак була, үзе уйларга, карарлар кабул итәргә күнегә, ахырга кадәр көрәшергә тырыша һәм уңышсызлыкларда төшенкелеккә бирелми.

Безнең мәктәптә дә  күп кенә балаларда шахмат уенына ныклы кызыксыну барлыкка килде. Күпчелек балалар буш вакытларында әлеге уенны алып, үзләренә иптәш табып уйныйлар. 3нче класс укучысы Мостафин Рәниф, аның апасы 5 нче класс укучысы Мостафина Чулпан район күләмендә үткәрелгән шахмат ярышларында гел призлы урыннарга лаек булалар.










# Безнең уңышлар

Балалар һәм яшүсмерләр театрларының “Сәйяр” фестивалендә катнаштык

һәм лауреат исеменә лаек булдык





Туфан Миңнуллин исемендәге II төбәкара фәнни-гамәли конференциядә

9 сыйныф укучыбыз Вәлиев Хәлим катнашты һәм 3нче дәрәҗәдәге дипломга лаек булды.













“Илһам" Бөтенроссия яшь язучылар бәйгесенең l турында

мәктәбебезнең 9 нчы сыйныф укучысы Вәлиев Хәлим һәм 8 нче сыйныф укучысы Ахметзянова Хәят җиңү яуладылар. Вәлиев Хәлим бәйгенең  апрель аенда үтәчәк йомгаклау турына да чакырулы.









Яхшы сүз-күңел ачкычы, ана теле- белем ачкычы

(татар халык мәкале)